КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2022 ел, 18 ноябрь г.Казань № б-2541

Татарстан Республикасының дәүләт бурычы белән нәтиҗәле идарә итү, бурыч сәясәтенең өстенлекләрен билгеләү максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасының бурыч сәясәтен расларга.

2. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Премьер-министры
Татарстан Республикасы А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 18 ноябрь, б-2541 нче
карары белән расланды

## 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасының бурыч сәясәте

2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасының бурыч сәясәте (алга таба – Татарстан Республикасының бурыч сәясәте) җаваплы бурыч сәясәтен гамәлгә ашыру һәм аның нәтиҗәлелеген арттыру, бурыч сәясәтенең өстенлекләрен билгеләү, Татарстан Республикасының дәүләт бурычы белән нәтиҗәле идарә итү һәм бюджетка бурычлар авырлыгын киметү буенча чаралар күрү максатларында әзерләнде.

Татарстан Республикасының бурыч сәясәте Татарстан Республикасы бюджет сәясәтенең состав өлеше булып тора һәм бюджетның балансльы үтәлешен тәэмин итүгә, Татарстан Республикасының дәүләт бурычын каплау һәм аларга хезмәт күрсәтү йөкләмәләрен һичшиксез үтәүгә, Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләре булуга бәйле бюджет рискларын киметүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашырудан гыйбарәт.

Татарстан Республикасының бурыч сәясәте кысаларында Татарстан Республикасының дәүләт бурычы күләмен оптималь дәрәҗәдә тоту, аңа хезмәт күрсәтү кыйммәтен минимальләштерү һәм Татарстан Республикасының дәүләт бурычына бәйле түләүләр вакытында тигез бүлү максатларында Татарстан Республикасының дәүләт бурыч алулары белән идарә итү стратегиясе гамәлгә ашырыла.

## Татарстан Республикасының бурыч сәясәтен гамәлгә ашыру йомгаклары

2022 елның 1 гыйнварына карата Татарстан Республикасы дәүләт бурычының гомуми күләме – 96,6 млрд.сум, шул исәптән: федераль бюджеттан бирелгән бюджет кредитлары буенча бурыч – 86,0 млрд.сум, дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләр 10,6 млрд.сум тәшкил итте. Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләренең хәзерге күләме һәм структурасы түбәндәге төп факторлар йогынтысында барлыкка килде. 2008 – 2009 елларның финанс-икътисад кризисы салган зыяннарны бетерү, аннан соң макроикътисад вәзгыяте катлаулану һәм кайбер актуаль проблемаларны хәл итү (корылык салган зыяннарны бетерүне тәэмин итү, монопрофильле муниципаль берәмлекләргә ярдәм күрсәтү) өчен 2014 – 2015 елларда икътисад үсешенең динамикасы әкренәю шартларында, Казан шәһәрендә 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиаданы һәм 2015 елгы Су спорт төрләре буенча XVI дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы указларын үтәү зарурлыгына бәйле рәвештә (барыннан да элек, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең аерым категорияләренә хезмәт

хакын арттыру өлешендә) Татарстан Республикасы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен федераль бюджеттан урта сроклы бюджет кредитларын җәлеп итү механизмы файдаланылды. Шулай ук 2020 елның декабрендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен федераль бюджеттан бюджет кредиты җәлеп ителде.

Федераль бюджет кредитлары буенча барлыкка килгән йөкләмәләр күләме йөкләмәләрне каплау срокларына карата бурыч портфеленең уңайлы структурасын тәэмин итү мәсьәләләренә даими игътибар таләп итте. Шуларны истә тотып, Татарстан Республикасы җыелган бурычны реструктуризацияләү кысаларында үткәрелгән чараларда даими катнашты. Шулай итеп, соңгы 5 ел эчендә түбәндәге чаралар башкарылды: 2017 елның октябрендә Казан шәһәрендә 2015 елгы су спорт төрләре буенча XVI дөнья чемпионатын һәм «Мастерс» категориясендә су спорт төрләре буенча XVI дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерлек чыгымнары чикләрендә бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдында булган Татарстан Республикасы бурычлары 2027 – 2036 елларда каплана торган итеп реструктурлаштырылды; 2017 елның декабрендә Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредитлары буенча бурычны реструктурлаштыру датасына түләнмәгән калдыклар чикләрендә бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдында булган Татарстан Республикасы бурычлары 2024 елга кадәр каплана торган итеп реструктурлаштырылды; 2020 елның июлендә бурычларны түли башлау срогын 2023 елдан 2025 елга күчереп һәм аларны 2034 елга кадәр тигез өлешләрдә каплап, бюджет кредитлары буенча, шул исәптән 2012 елда реструктурлаштырылган кредитлар буенча (монопрофильле муниципаль берәмлекләргә ярдәм күрсәтүгә бирелгән кредитларны исәпкә алмыйча) һәм 2017 елның декабрендә бурычларны кире кайтару чорын 2029 елга кадәр озайтып реструктурлаштырылган кредитлар буенча Россия Федерациясе алдында булган Татарстан Республикасы бурычын каплау чоры күчерелде (озынайтылды); 2021 елның июлендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларын каплау өчен бюджет кредитлары буенча бурычларны реструктурлаштыру датасына түләнми калган акча чикләрендә бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдында булган Татарстан Республикасы бурычлары 2029 елга кадәрге чорда түләнә торган итеп реструктурлаштырылды.

Моннан тыш, хәзерге вакытта федераль дәрәҗәдә кабул ителгән карар нигезендә 2017 елның декабрендә реструктурлаштырылган бюджет кредитлары буенча һәм 2021 елның июлендә реструктурлаштырылган кредит буенча Россия Федерациясе алдында булган Татарстан Республикасының реструктурлаштырылган бурычларын каплау срокларын 2022 елдан 2029 елга күчерү рәсмиләштерелә.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасының элеккечә үк финанс базарларында кредит оешмаларыннан кредитлар рәвешендә акча алуга һәм дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен чыгаруга мөрәҗәгать итмәвен билгеләп үтәргә кирәк.

Әлеге чаралар, бурычларның каплау срогын озак вакытка бүлеп, Татарстан Республикасы бюджетына төшә торган, элегрәк җәлеп ителгән кредитларны кире кайтаруга шактый акча тоту зарурлыгы белән барлыкка килгән авырлыкны 2025 елга кадәр шактый киметергә мөмкинлек бирде.

Шул ук вакытта, хәзерге вакытта 2020 елда федераль бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрне (бурычларны) түләү чорын күчерү (озайту), шулай ук 2021 елда бюджет кредитын реструктурлаштыру кысаларында федераль дәрәҗәдә кабул ителгән карарлар нигезендә федераль бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы бурычының шактый өлешен якынча 72,9 млрд.сум күләмендә планлы рәвештә исәптән төшерү мөмкинлеге бар. Әлеге бурычларны исәптән чыгару бары республика территориясендә федераль дәрәҗәдә хупланган, республика бюджеты акчасы исәбеннән инфраструктурасын тәэмин итүгә тиешле йөкләмәләр кабул ителгән берничә яңа инвестицион проектлар гамәлгә ашырылганда мөмкин була. Республиканың федераль бюджетка булган бурычын исәптән төшерү хокукы федераль бюджетка аның кайбер керем чыганаклары буенча яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашырудан фактта кергән акча күләмендә бирелә.

2022 елда федераль бюджеттан озак срокка акча җәлеп итү кысаларында Татарстан Республикасы инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү өчен федераль бюджеттан бюджет кредиты кебек инструмент куллана башлады. 2022 ел йомгаклары буенча шул рәвешле бирелгән акчаның гомуми суммасы 2024 – 2037 елларда каплау срогы һәм бюджет кредитын файданланган өчен елга өч процент күләмендә процент ставкасы белән 14,3 млрд.сум тәшкил итәчәк.

Дәүләт бурычының гомуми күләмен контрольдә тоту кысаларында Татарстан Республикасының дәүләт гарантияләрен бирүгә карата аз күләмдә бирү сәясәте алып барылды. Хәзерге вакытта дәүләт гарантияләре өлешендә Татарстан Республикасының дәүләт бурычы Яр Чаллы шәһәренең шәһәр төзү предприятиесе – «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыятенең федераль бюджет алдындагы йөкләмәләре буенча бирелгән гарантия буенча аның 2005 елда инвестиция үсешенә алынган кредит буенча чит ил партнерларына булган бурычын озак срокка исәпләнгән реструктурлаштыру үткәргәндә ярдәм күрсәтү кысаларында 10,071 млрд. япон иена (2022 елның 1 ноябренә карата Россия Банкының рәсми курсы буенча исәпләгәндә 4,2 млрд.сум) күләмендә йөкләмә рәвешендә бирелде. Бюджет законнарына үзгәрешләр кертү дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләр күләмен шактый киметүгә йогынты ясавын билгеләп үтәргә кирәк, алар принципалның Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы составында Россия Федерациясе субъектының дәүләт гарантиясе белән тәэмин ителгән факттагы йөкләмәләре суммасында дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрне исәпкә алырга мөмкинлек бирә. Соңгы елларда яңа дәүләт гарантияләре бирелмәде. Аларны 2022 елда да бирү каралмаган.

2022 елның 1 ноябренә Татарстан Республикасы дәүләт бурычының гомуми күләме 97,6 млрд.сум тәшкил итте. Валюта базарында тотрыклы вәзгыять саклангандa (Россия акчасының чит ил валюталарына карата курсы кискен үзгәрмәгәндә), агымдагы дәрәҗә белән чагыштырганда, Татарстан Республикасының дәүләт бурычы күләмен арттыру инфраструктура бюджет кредитын җәлеп итүгә бәйле рәвештә планлаштырыла. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы бюджетына бурыч авырлыгы күрсәткеченең зурлыгы (дәүләт бурычы күләменең еллык салым һәм салым булмаган керемнәр күләменә нисбәте) 50 процент дәрәҗәсеннән артмаячак, бу бурыч тотрыклылыгының югары критерийларыннан берсе булып тора.

Санап үтелгән факторлар (бурычлар йөкләмәләрен каплау буенча түләүләрне елларга бүленешен исәпкә алып) Татарстан Республикасы бюджетына төшә торган

авырлыкны уртача дәрәҗәдә саклап калырга һәм бурычның әлеге күләменә бәйле булган бюджет рискларын киметергә ярдәм итәчәк.

2022 елда Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән бәяләү нигезендә Татарстан Республикасы һаман да бурыч тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган Россия Федерациясе субъектлары төркеменә карый.

Татарстан Республикасы бурыч сәясәтенең характерын
һәм юнәлешләрен билгели торган төп факторлар

Бурыч сәясәтенең характерын һәм юнәлешләрен билгели торган төп факторлар:

«дус булмаган» чит ил дәүләтләре ягыннан тышкы сәяси хәл йогынты ясавын һәм санкция басымы дәвам итә торган агымдагы тотрыксыз икътисадый вәзгыять шартларында һәм икътисадта чагыштырмача уртача сроклы тенденцияләрнең билгесезлеге югары булганда, икътисадны стабильләштерү һәм халыкка социаль ярдәм күрсәтү чараларын исәпкә алып, балансланган бюджет булдыру һәм аны үтәү сәясәтен гамәлгә ашыру зарурлыгы;

Россия Федерациясе Финанс министрлыгының бурыч тотрыклылыгын бәяләү системасы нигезендә бурыч тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган Россия Федерациясе субъектлары төркемендә позицияне саклап калу зарурлыгы;

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы белән бюджет кредитларын реструктурлаштыру турындагы килешүләрдә билгеләнгән шартларны һичшиксез үтәүне тәэмин итү зарурлыгы;

регионнарның инвестицион эшчәнлеген стимуллау һәм аларны социаль-икътисадый үстерү өчен дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләгән тәртиптә сайлап алынган инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү өчен федераль бюджеттан бюджет кредитлары (алга таба – инфраструктура бюджет кредитлары) бирү программасында катнашу.

Татарстан Республикасы
бурыч сәясәтенең максатлары һәм бурычлары

Татарстан Республикасының бурыч сәясәте түбәндәге максатларга ирешүгә юнәлдерелгән:

Татарстан Республикасы бюджетының бурыч тотрыклылыгын саклаганда Татарстан Республикасы бюджетының балансылыгын тәэмин итү;

дәүләт бурычы һәм аңа хезмәт күрсәтү чыгымнары күләмен контрольдә тотарга мөмкинлек бирә торган икътисади куркынычсыз дәрәҗәдә Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләре күләмен саклау;

федераль бюджеттан бюджет кредитларын реструктурлаштыру турындагы килешүләрдә билгеләнгән шартларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджетына төшә торган бурыч авырлыгын уртача дәрәҗәдә саклау;

Татарстан Республикасы дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү кыйммәтен минимальләштерү;

башка чыгым йөкләмәләренең барысын да үтәгәндә Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен үз вакытында тулы күләмдә үтәүне тәэмин итү.

2023 – 2025 елларда бурыч сәясәте Татарстан Республикасы йөкләмәләрен һичшиксез үтәүгә, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән нормаларны һәм чикләүләрне башкаруга юнәлдереләчәк һәм республика бюджетына төшә торган бурыч авырлыгын Россия Федерациясенең бурыч тотрыклылыгы югары булган субъектларына Татарстан Республикасы кертеп карала торган дәрәҗәдә тотуга юнәлтелгән.

Татарстан Республикасы бурыч сәясәтенең төп бурычлары:

Татарстан Республикасы дәүләт бурычы күләмен федераль законнарда билгеләнгән чикләрдә һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә тәэмин итү;

республика позициясен Россия Федерациясенең бурыч тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган субъектлары төркемендә саклап калуны тәэмин итә торган бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләренең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү чыгымнарын федераль законнарда билгеләнгән чикләрдә һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә тәэмин итү;

акча алу турында карар кабул итүнең Татарстан Республикасы бюджетының реаль ихтыяҗлары белән үзара бәйләненешен тәэмин итү юлы белән заем акчасын җәлеп итүдә нигезсез акча алуларны булдырмау;

инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына кирәкле бюджет кредитлары күләмнәрен җәлеп итүне тәэмин итү;

бюджет кредитлары буенча бурычларны исәптән чыгаруны тәэмин итү өчен норматив хокукый актларда каралган инструментлардан файдалану;

түләү срокларын тигез бүлгәндә аңа хезмәт күрсәтү кыйммәтен минимальләштерүне тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт бурычы структурасын тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт бурычы турында мәгълүматны исәпкә алу, Татарстан Республикасы дәүләт бурыч йөкләмәләре турында хисаплылык формалаштыру;

Татарстан Республикасы дәүләт бурычы турында мәгълүмат ачуны тәэмин итү.

## Татарстан Республикасының дәүләт бурыч алулары өлкәсендә сәясәт

Яңа өч еллык циклда элек үткәрелгән бурыч сәясәтенең төп юнәлешләре дәвам ителәчәк. Татарстан Республикасы дәүләт бурычы буенча операцияләр өлешендә эшләү киләсе чорда тулаем гамәлгә ашырыла торган бюджет сәясәте белән турыдан-туры бәйле булачак.

Чираттагы финанс елында һәм план чорында кредит оешмаларыннан һәм дәүләт кыйммәтле кәгазьләреннән кредитлар рәвешендә Татарстан Республикасы дәүләт бурыч алуларын гамәлгә ашыру элеккечә каралмый.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан үткәрелә торган, төбәкләрдә инвестицион активлыкны стимуллаштыруга юнәлдерелгән сәясәтне исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сайлап алынган инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү өчен федераль бюджеттан инфраструктура бюджет кредитларын елына өч процент ставка белән 15 елга җәлеп итү мөмкинлеген файдалану дәвам ителәчәк. Инфраструктура кредитларын файдалануның төп максаты – республиканың инфраструктура үсешенә стимул бирү, өстенлекле инфраструктура сегментларында проектларны финанслау, төп чаралар объектларына хосусый инвестицияләр җәлеп итү, яңа эш урыннары булдыру һәм төбәкнең икътисади потенциалы үсү мөмкинлеге.

Татарстан Республикасының дәүләт бурыч алулары өлкәсендә сәясәт, финанс базарында гамәлгә ашырылган бурыч алулар буенча йөкләмәләр булмаганда, федераль бюджеттан алынган бюджет кредитларын түләү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча Татарстан Республикасы йөкләмәләрен шартсыз үтәүгә юнәлдереләчәк. Федераль дәрәҗәдә Россия Федерациясе субъектларына бюджет кредитлары рәвешендә федераль бюджет акчасын бирү турында карарлар кабул ителгән очракта, әлеге фактор, кире кайтару шарты белән акча җәлеп итү вариантларын караганда, өстенлекле әһәмияткә ия булачак.

Татарстан Республикасы бурыч сәясәтен гамәлгә ашыру өчен керемнәр арту өлкәсендә уңай нәтиҗәләргә ирешү, базар мөнәсәбәтләрендә бурычка акча җәлеп итү мәсьәләсенә консерватив якын килү алымын тәэмин иткәндә республика бюджетының чыгым өлешен һәм кытлык дәрәҗәсен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру шактый зур әһәмияткә ия булачак.

2023 – 2025 елларда Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән хезмәттәшлек итү кысаларында бюджетның бердәм счетында калган акчаны тулыландыруга бюджет кредиты алу мөмкинлеген карау дәвам итәчәк. Мондый кредит акчасына ихтыяҗ законнарда каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән тормышка ашырыла торган социаль йөкләмәләрне шартсыз үтәү өчнг бюджет лвидлылыгын яхшырту зарурлыгы булганда барлыкка килергә мөмкин. Әлеге инструмент финанс елы йомгаклары буенча дәүләт бурычы күләмен арттыру мөмкинлеген күздә тотмый, ул республика бюджеты ликвидлыгын саклау һәм бюджет чыгымнарын берникадәр тигез, бер ритмда үтәү өчен яхшы альтернатива булып тора һәм бюджетның керем өлешен тәэмин итү кысаларында катлаулы мәсьәләләр барлыкка килгән очракта файдаланылырга мөмкин.

Татарстан Республикасының
бурыч сәясәтен гамәлгә ашыру инструментлары

Татарстан Республикасы бурыч сәясәтен тормышка ашыру инструментлары:

Татарстан Республикасы дәүләт бурычы параметрларының Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән чикләүләргә туры килүен мониторинглау;

бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләрне (бурычларны) реструктурлаштыру кысаларында Татарстан Республикасы тарафыннан кабул ителгән йөкләмәләрне үтәү һәм республиканың бурыч йөкләмәләрен үз вакытында һәм тулысынча каплауны һәм аларга хезмәт күрсәтүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы бюджетына төшә торган бурыч авырлыгын яраклы дәрәҗәдә саклап калуны тәэмин итү максатларында, финанс базарларында акча җәлеп итү механизмын кулланмыйча (коммерция оешмаларыннан кредитлар рәвешендә коммерция характерындагы акча һәм облигация заемнарын алудан башка), үз чыганаклары исәбеннән бюджет кытлыгын өстенлекле каплау. Әгәр бюджетны үтәү барышында, башка финанслау чыганаклары булмаганда, аның керем өлешен тулыландыру белән бәйле шартлар шактый начарайган очракта, әлеге алымны үзгәртү мөмкинлеген карарга була;

федераль дәрәҗәдә тиешле карарлар кабул иткәндә – бюджет кредитлары рәвешендә бирелә торган федераль бюджет акчасын алу мөмкинлеген җентекле карарга һәм тәҗрибәдә кулланырга, шул исәптән инфраструктура проектларын тормышка ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль кредитлар кебек озак вакытка исәпләнгән финаслау инструментын файдалану;

законнарда каралган, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән тормышка ашырыла торган социаль йөкләмәләрне һичшиксез үтәү өчен бюджет ликвидлыгын яхшырту зарурлыгы барлыкка килгәндә – бюджетның бердәм счетында калган акчаны тулыландыруга бюджет кредиты кебек инструмент кысаларында акча җәлеп итү мөмкинлеген карау;

Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча бурыч йөкләмәләре күләмен контрольдә тотуны һәм принципаллар тарафыннан гарантияләнгән йөкләмәләрне тулы күләмдә һәм билгеләнгән срокларда үтәүне мониторинглауны гамәлгә ашыру;

озак сроклы чорда республика бюджетын баланслауны тәэмин итү максатларында бюджет керемнәрен арттыруга, бюджет чыгымнарын оптимальләштерүгә, бюджетны планлаштыру һәм бюджетны үтәү сыйфатын яхшыртуга, тотрыклы керем чыганаклары белән тәэмин ителмәгән яңа чыгым йөкләмәләрен кабул итүне булдырмауга юнәлдерелгән чараларны планлы һәм эзлекле рәвештә гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планын раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1194 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт финансларын савыктыру чаралары планында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 14 гыйнвар, б-10 нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт бурычын киметү чаралары планында каралган чараларны алга таба тормышка ашыру;

Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирү мәсьәләләрен карап тикшергәндә – гарантияләрнең сыйфатына карата югары таләпләр куеп, һәрьягы исәпкә алынган сәясәт үткәрү принцибын саклау. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы бюджетына төшә торган бурыч авырлыгын арттыруны бетерү максатларында 2023 – 2025 елларда Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирү планлаштырылмый;

2020 елда үткәрелгән федераль бюджет кредитлары буенча йөкләмәләрне (бурычларны) каплау чорын күчерү (озынайту) шартларының, шулай ук 2021 елда үткәрелгән бюджет кредитын реструктурлаштыру шартларының үтәлеше тәэмин ителгәндә, алга таба федераль бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы

бурычының бер өлешен яңа инвестиция проектларын тормышка ашырудан федераль бюджетка кергән факттагы салым керемнәре күләмендә исәптән төшерү.

## Татарстан Республикасының
## бурыч сәясәтен гамәлгә ашыру күрсәткечләре

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы белән төзелгән килешүләр нигезендә 2022 елның йомгаклары буенча иң күбе 47 процент дәрәҗәсеннән 2025 елның йомгаклары буенча иң күбе 40 процент дәрәҗәсенә кадәр ел саен эзлекле рәвештә киметү буенча йөкләмәләргә игътибар итеп, 2023 – 2025 еллар чорына Татарстан Республикасының гомуми бурыч йөкләмәләре күләме өлешен, тиешле елга кире кайтарылмый торган кертемнәрне исәпкә алмыйча, бюджет керемнәренең еллык суммасының 50 процентыннан түбәнрәк саклап калуны тәэмин итү Татарстан Республикасының бурыч сәясәте чараларын гамәлгә ашыруның төп, шул исәптән Татарстан Республикасы тарафыннан 2020 елның июлендә бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасының Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләрен (бурычларын) түләү чорын күчерү (озайту) кысаларында кабул ителгән йөкләмәләрне үтәргә һәм бурыч тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган Россия Федерациясе субъектлары төркеменә кертеп карарга мөмкинлек бирә торган күрсәткечләреннән берсе булып торачак.

Шулай ук 2017 елда үткәрелгән һәм 2020 елда өстәмә килешү белән озынайтылган федераль бюджеттан бирелгән бюджет кредитларын реструктурлаштыру турында килешү нигезендә 2023 – 2025 елларда Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре суммасының иң күбе 10 проценты дәрәҗәсендә (әлеге күрсәткечне норматив хокукый актларда каралган нигезләрдә арттыру мөмкинлеген исәпкә алып) саклауны , иң элек, үз чыганаклар исәбеннән каплап тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмендә Татарстан Республикасы дәүләт бурычына хезмәт күрсәтүгә чыгымнар өлешен түбән дәрәҗәдә саклап калу Татарстан Республикасы бурыч сәясәте чараларын нәтиҗәле гамәлгә ашыруның бурыч йөкләмәләренә хезмәт күрсәтү кыйммәтен минимальләштерүне чагылдыра торган тагын бер күрсәткече булып торачак, ул 2023 – 2025 елларда Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләменең бер процентыннан артмаска тиеш.

Моннан тыш, Татарстан Республикасын бурыч тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган Россия Федерациясе субъектлары төркеменә кертү максатларында, чираттагы финанс елның 1 гыйнварына барлыкка килгән Татарстан Республикасы дәүләт бурычын каплау һәм аңа хезмәт күрсәтү буенча түләүләрнең еллык суммасы 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан дотацияләрнең гомуми күләменә карата, чираттагы финанс елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварыннан соң каплау срогы белән бурыч йөкләмәләрен вакытында алда түләүгә җибәрелә торган түләүләрне исәпкә алмыйча, 13 проценттан артмаска тиеш.

Бюджет өчен Татарстан Республикасы дәүләт бурычы белән идарә итү процессында барлыкка килә торган рискларны анализлау

Татарстан Республикасы бурыч сәясәте максатларына ирешүдә аны гамәлгә ашыру процессында барлыкка килә торган потенциаль рискларны бәяләү мөһим урын алып тора. Элеккечә дәүләт бурычы белән идарә иткәндә бурыч политикасының эффективлыгына йогынты ясый торган төп рисклар:

бюджет керемнәренең планлаштырыла торган керүләр күләмнәренә, шул исәптән геосәясәт һәм тышкы икътисадый факторларның тискәре йогынтысы аркасында икътисади хәл начараюга бәйле рәвештә ирешмәү рискы. Керемнәрнең кереп бетмәве бюджетның кабул ителгән чыгым йөкләмләрен үтәү һәм аның балансылыгын тәэмин өчен альтернатив чыганаклар эзләргә таләп итә;

ликвидлык рискы – бюджетның бердәм счетында чыгым һәм бурыч йөкләмәләрен билгеләнгән срокта тулысынча үтәү өчен кирәкле акча булмау;

гарантия очрагы башлану рискы – принципалларның Татарстан Республикасы тарафыннан гарантияләнгән йөкләмәләр буенча акча түләмәве;

бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасының Россия Федерациясенә булган бурычларын реструктурлаштыру шартларын үтәмәү рискы.

Татарстан Республикасының бурыч сәясәтен гамәлгә ашыруга бәйле рисклар белән идарә итүгә карата кулланыла торган төп чаралар:

бурычларны алган вакытта барлыкка килә торган потенциаль рискларны ачыклау, мониторинг үткәрү һәм бәяләү;

бурыч рисклары белән бәйле югалтулар мөмкинлеген минимальләштерү буенча чаралар күрү;

республика бюджеты керемнәрен һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне дөрес фаразлауны гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы бюджетының балансы булмавы барлыкка килүне булдырмауга юнәлдерелгән, һәрьяклап исәпкә алынган һәм нигезләнгән карарлар кабул итү.

---